ГЛАВА ЮТАЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дмитрова, д.2,
с.Ютаза, 423962

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЮТАЗЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Дмитров урамы, 2 йорт,
Ютазы авылы, 423962

Тел.:(85593) 4-00-91, факс:4-00-93, e-mail: Utaz.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**17 ноябрь 2022 ел** **№ 6**

Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенә керүче Ютазы торак пунктында 2023 елдаүзара салым кертү һәм ул акчаларны куллану мәсьәләләре буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2022 елның 18 ноябрендә 17.00 сәгатькә ТР, Ютазы муниципаль районы, Ютазы торак пункты, Дмитров ур., 9 йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында (авыл мәдәният йорты) Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге Ютазы торак пунктында 2023 елда гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. Җыенга чыгарылган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге Ютазы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I һәм II төркем инвалидлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче Бөек Ватан сугышы ветераннары, Украинада махсус хәрби операциядә катнашучылардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә сез ризамы һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, ягъни түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү белән килешәсезме:

-Ютазы торак пунктында Камалиев урамы буенча юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү(юллар төзү, төзелеш материаллары сатып алу, ташу, ташу, асфальтлау, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Ютазы торак пунктында Димитров урамы буенча юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (юллар төзү, төзелеш материаллары сатып алу, ташу, асфальтлау, килешү буенча эшләргә түләү);

- Ютазы торак пунктын төзекләндерү (коры агачларны, куакларны кисү, территорияне җыештыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Урам яктырткычларын ремонтлау (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Ютазы торак пунктында зират территориясендә киртәләрне ремонтлау (төзелеш материалларын сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Ютазы торак пунктында авыл эчендәге юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту, шартнамә буенча эшләр өчен түләү)

« РИЗА» «КАРШЫ».

3. Ютазы авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

4. Әлеге карарны Ютазы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында ( http:// jutaza.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар бастырылган көннән үз көченә керә.

Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлеге башлыгы Р.М.Галимов